ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.05.2025 с.Старое Дрожжаное № 145

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 853 (06.05.2019 N 380, 16.04.2020 N 294, 01.09.2020 N 768, 03.11.2020 N 989, 21.07.2021 N 633, 26.07.2021 N 645, 30.10.2021 N 1030, 26.05.2022 N 489, 20.06.2022 N 587, 14.09.2022 N 1002, 30.11.2022 N 1268, 17.07.2023 № 846, 03.04.2024 № 215, 26.04.2024 № 283, 21.06.2024 № 447, 12.09.2024 № 766, 18.04.2025 № 245 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары кертелгән үзгәрешләр белән) номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының гамәлен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларына таратырга

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләренә:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган коллектив шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә әлеге карарда билгеләнгән җитди хезмәт шартларын үзгәртү турында хәбәр итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 30 гыйнварындагы 22 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов